Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Советы

КАРАРЫ

26 июнь 2024 ел № 101

Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, үзләренең вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә

Иске Ммихайловка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 05 декабрендәге 61 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 9 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 58 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 64 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба - Тәртип) хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары» кушымтасының I бүлегенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башлык, башлык урынбасарының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә муниципаль берәмлек башлыклары өчен хезмәткә түләүнең унберенче төркеменә кертелгән

нормативтан артып китә алмый - елына 12,86 айлык акчалата түләү, аларның урынбасарлары өчен - елына 12,77 айлык акчалата бүләкләү.»;

1.2. Тәртипнең II бүлеге 6 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфасының исеме | Вазыйфаи оклад<br>(12 төркем өчен хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 18 253 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 17 720» |

1.4. Карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфасының исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме<br>(12 төркем өчен хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 18 260 |
| Башлык урынбасары | 13 324» |

2. Әлеге карарны Әлмәт районы,Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, Лесная йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Михайловка
авыл җирлеге Башлыгы — А.Ю.Зарубин